ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2024г. с.Старое Дрожжаное № 33

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законна таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2021 елның 27 маендагы 9/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2024 елның 12 ноябрендәге 01-09-22526 номерлы мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының « Городище авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы – коллегиаль киңәшмә орган составын расларга:

1) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов;

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Р.Р. Баһаветдинов;

3) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе И.Р. Хәйруллин;

4) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге башлыгы И.М. Хөсәенов;

5) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы Ю.И. Шуркин;

6) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Городище авыл җирлеге башлыгы Н.А. Усмендеев;

7) «Татарстан Республикасы пространство белешмәләре фонды» ДБУ вәкиле (килешү буенча).

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына гавами тыңлауларны оештыручыга җирле үзидарә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү кызыксынган затларга аларны үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр – бер айдан да артык түгел һәм 2024 елның 16 декабреннән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында (www.droganoye.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Чүпрәле муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Е. Ярухин